ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЕЛАБУЖСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** 24.02.2025 413 **КАРАР**

Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «2025 елга Алабуга муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның туклануын тәэмин итү турында» 2024 елның 27 декабрендәге 2220 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Гомуми белем бирү учреждениеләрендә, башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләрендә укучыларны тукландыруны оештыруга Санитар - эпидемиологик таләпләр» СанПиНның 2.3/2.4.3590-20 номерлы балаларны социаль яклау, аларның сәламәтлеген ныгыту, белем бирү учреждениеләрендә укучыларны балансланган кайнар аш белән тәэмин итү нормаларын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Алабуга муниципаль районы Башкарма комитетының «2025 елга Алабуга муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның туклануын тәэмин итү турында» 2024 елның 27 декабрендәге 2220 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 2 бүлегендәге 2.4. пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«-шикәр диабеты белән авыручы бер укучы баланы индивидуаль тукландыруның уртача бәясенең күләме - 69 сум 43 тиен.».

1.2. Нигезләмәнең 3 бүлегендәге 3.3.3 пунктында д) пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«д) хәрби хезмәткәрләр, хәрби хезмәт узу чорында яки хәрби хезмәттән азат ителгәннән яисә контракт туктатылганнан соң аларга гариплек (яралану, хәрби травма алу, контузия алу) аркасында инвалидлык билгеләнгән яки авыру алынган булса, шулай ук махсус хәрби операция нәтиҗәсендә һәлак (үлгән) булганнарның балаларына:

- хәрби хезмәткәрнең гариплек (яралану, хәрби травма алу, контузия алу) нәтиҗәсендә һәлак булуы (үлеме) турында раслаучы хәбәр итү кәгазе (хәбәрнамә) күчермәсе;

- хәрби хезмәткәрнең инвалидлыгы яки авыруы турында белешмә;

- гарипләнү (яралану, хәрби травма алу, контузия алу) турында белешмә;».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Алабуга муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче

ДОКУМЕНТ ПОДПИСАН ЭЛЕКТРОННОЙ ПОДПИСЬЮ

СВЕДЕНИЯ О СЕРТИФИКАТЕ ЭП

Сертификат: 4DF13A255AE51927759AA463F36F11E0
Владелец: Ахмадеева Эльмира Равильевна
Действителен с 09.01.2025 до 04.04.2026

Р.Э. Әхмәдиева


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН